ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

18.10.2019 № 961

2020 елга Нурлат муниципаль районы балаларын йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативларын раслау турында

1. 2019 елга түбәндәге кушымталарны расларга:

- 2020 елга гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативлары;

- гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү хакын исәпләү тәртибе турында нигезләмә.

2. Нурлат муниципаль районының «Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесенә гомуми белем бирү оешмалары укучыларын әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясенең нормативларына туры китереп, гомуми белем бирү оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Л.Н. Маняпов

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 ел, 18 октябрь, 961 номерлы карары белән расланды

2020 елга гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативлары

| Автотранспорт чарасы моделе исеме | Ике ставкалы нормативның күләме | |
|---|---|---|
| | бер автотранспорт чарасына ставка, елга сум | автотранспорт чарасының бер чакрымына ставкасы, сум |
| КАВЗ | 116398 | 37,42 |
| ПАЗ | 116656 | 37,35 |
| ГАЗ «Газель» | 110767 | 30,41 |
| УАЗ | 110314 | 29,04 |
| FIAT | 110057 | 27,47 |
| Peugeot Boxer | 110572 | 27,11 |
| Ford Transit | 110829 | 30,37 |
| Камаз Марко-Поло3297 | 119128 | 35,31 |

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 ел, 18 октябрь, 961 номерлы карары белән расланды

# Гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү хакын исәпләү тәртибе турында нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү механизмын билгели (алга таба - муниципаль хезмәт).

1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативы, автотранспорт чаралары саны һәм автотранспорт чараларының фактик пробегы нигезендә хисап чорында исәпләнә.

1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары ел саен «Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан раслана.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен формалаштырганда автотранспорт чараларының фактик узган юлы турындагы мәгълүмат Татарстан Республикасында автотранспорт чараларының аерым төрләрен мониторинглауның бердәм системасы мәгълүматлары буенча автотранспорт чарасы маршрутының расланган паспорты кысаларында хисап елы өчен автотранспорт чарасының фактта узган юлы буларак кабул ителә.

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясенең исәп-хисабы

2.1. Муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәтләр күрсәтү бәясе түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$S_i = \sum_{m=1}^{k} (n_{f\,m} \times NF_{km_m} + NF_{as\,m} \times M_m)$$

монда:

$S_i$- муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе;

$n_{f\,m}$ - m моделе автотранспорт чараларының фактик пробегы, километр;

$NF_{km\ m}$ - бер километрга гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру бәясе нормативы ставкасы, сум;

$NF_{as\ m}$ - гомуми белем бирү оешмалары укучыларын бер автотранспорт чарасына йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру бәясе нормативы ставкасы, сум;

$M_m$- m моделе автотранспорт чаралары саны, берәмлек;

m - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус моделе атамасы;

k - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус модельләре саны.